**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«25» июль 2023 ел Боерган авылы № 35/1

Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычларны түләтүгә өметсез дип
тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, җирлек уставы нигезендә Боерган авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки гражданлык процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны үлгән дип игълан итү, әгәр закон буенча да һәм васыять буенча да варислар булмаса яисә варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яки барлык варислар да мирас алудан читләштерелгән, яисә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яисә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

2) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

3) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Боерган авыл җирлегенең 2020 елның 13 октябрендәге 3/1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//prav.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Г.Г.Минакова